ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 183 2 апрель 2019 ел

## 2019 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән саклык чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 апрелендәге «Янгынга каршы режим турында» 390 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 13 мартындагы «2019 елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 180 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. 2019 елның 15 апреленнән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә янгын куркынычы сезоны башлануын билгеләргә.

2. Барлык милек формасындагы предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына һәм торак-коммуналь хуҗалык идарәче компанияләре җитәкчеләренә:

- ведомство карамагындагы объектларда территорияне коры үләннән һәм чүп-чардан чистарту буенча чаралар күрергә;

- balансta булган тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерү;

- янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы булган эшләрне чикләргә;

- урман массивлары буенда минеральләштерелгән саклау полосаларын булдыру һәм ирекле янгын формированиеләре әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын оештыру буенча чараларны тормышка ашырырга;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрендә ачык утны куллану һәм учаклар ягу тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы боерыгын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

3. Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләре рәисләренә, балаларның ялын һәм аларны савыктыруны (шул исәптән балалар көндез була торган) оештыручы оешма җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урнашкан, урман кишәрлекләре белән чиктәш булган (кушымта) икътисад объектлары һәм сәламәтләндерү оешмалары җитәкчеләренә янгын куркынычы сезоны вакытында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтү эшчәнлеге бүлегенә (Р.Ф.Насыйбуллин) Түбән Кама янгын-коткару гарнизоны башлыгы (А.С.Карасев) белән берлектә тәкъдим итәргә.):

- саклану янгын-профилактика чаралары комплексын планлаштырырга һәм үткәрергә;

- гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре территорияләренең, балалар сәламәтләндерү лагерьларының янгынга каршы торышын тикшерүне уткәрергә;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим таләпләрен, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрендә ачык утны куллану һәм учаклар ягу тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы боерыгын исәпкә алып, коры үлән яндыру тәртибен аңлату эшен оештырырга һәм үткәрергә;

- гражданнарның урман янгыннары куркынычы янаган бакчачылык (яшелчәчелек, дача) коммерцияле булмаган берләшмәләрендә тиешле профилактик эшне оештырырга һәм үткәрергә.

5. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (Р.М.Шәйдуллин):

- коры үлән яндыру, гражданнар тарафыннан ачык ут куллануны көн саен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен, шулай ук муниципаль районда урнашкан җирлекләр башлыклары, бакчачылык берләшмәләре рәисләре, авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм башка оешмалар җитәкчеләре белән янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозып, камыл, коры үлән һәм чүп-чар яндыруга юл куймау турында аңлату эшләрен оештыру һәм үткәрү өчен ведомствоара төркем төзергә.

6. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (А.Г.Нигъмәтҗанов):

- авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә язгы-җәйге янгын куркынычы чорында халык арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын агитацияләү һәм пропагандалау буенча эш алып барырга, шул исәптән бу юнәлештә гаммәви мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек оештырырга. Торак пунктлар чикләрендә чүп-чардан һәм коры-сарыдан территорияне чистарту эшен оештырырга;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (М.Б.Миңнуллин) белән берлектә торак пунктларда һәм урман массивларында янгыннарны булдырмау максаты белән, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә камыл, корыган үләнне, чүп-чарны санкциясез яндыруны кисәтү һәм ачыклау эшен оештыру. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрендә ачык ут куллану һәм учаклар ягу тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы боерыгы таләпләрен җиткерергә.

7. «Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ (И.Н.Рзай), «Түбән Кама урманчылыгы» ДКУ (А.Ф.Гыймадиев) Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге (Р.Ф.Насыйбуллин) (килешү буенча), Түбән Кама янгын-коткару гарнизоны (А.С.Карасев) (килешү буенча) белән берлектә, 2019 елның 15 апреленнән 10 маена кадәр, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өлешендә, урман-парк зоналарына һәм гражданнарның массакүләм ял итү урыннарына патрульлек итүне оештыру һәм үткәрү.

8. Урман-парк зоналарына һәм гражданнарның күпләп ял итү урыннарына патрульлек итү чорында Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенә «Түбән Кама урман хуҗалыгы» ДБУ (И.Н.Рзай), «Түбән Кама урманчылыгы» ДКУ (А.Ф.Гыймадиев), Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтү эшчәнлеге бүлеге (Р.Ф.Насыйбуллин) һәм Түбән Кама янгын-коткару гарнизонына (А.С.Карасев) законнарда каралган тәртиптә ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

9. Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ГМЧ белән элемтә бүлегенә (М.В.Камелина) гаммәви мәгълүмат чараларында торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең проблемалы мәсьәләләрен яктыртуны, шулай ук халыкка янгын куркынычы чорында янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Шәйдуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары Р.Ә. Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 2-нче апрель
183-нче номерлы карарына
кушымта

Урман янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар
исемлеге

- Красный Ключ поселогы.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, гражданнарның
урман кишәрлекләре белән чиктәш бакчачылык,
яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләре
исемлеге

- «Нефтехимик» бакчачылык кулланучылар кооперативы.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан,
урман кишәрлекләре белән чиктәш балаларның ялын һәм аларны савыктыруны
(шул исәптән көндез була торган) оештыручы оешмалар
исемлеге

- «Чайка» балалар сәламәтләндерү лагере;
- «Юность» балалар сәламәтләндерү лагере;
- «Олимпиец» спорт сәламәтләндерү лагере;
- «Заря» балалар сәламәтләндерү лагере;
- «Кама» балалар сәламәтләндерү лагере;
-«Зәңгәр Күл» балалар сәламәтләндерү лагере;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан,
урман кишәрлекләре белән чиктәш сәламәтләндерү оешмалары
исемлеге

- «Корабельная роща» санаторий-профилакторий.